**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**
**Балтачевского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Балтач**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ул. Школьная, 1, с. Балтачево,**
**Камско-Устьинский район, 422829**
**тел./факс: (884377) 3-66-40**
**ОГРН 1061672018044**
**ИНН/КПП 1622004637/162201001**

**Мэктэп урамы, 1, Балтач авылы,**
**Кама Тамагы районы, 422829,**
**тел./ факс: (884377) 3-66-40**
**ОГРН 1061672018044**
**ИНН/КПП 1622004637/162201001**

**КАРАР**

**«28» августа 2018 года** **№4**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 28 июнендәге “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 3 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 28 июнендәге 3 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.4 пунктына 8, 9 пунктчасыларын өстәргә:

“8) муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәләре буенча документлар тапшыру срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт курсәтүен туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса.”;

1.2. 5 бүлекнең 5.12 пунктындагы 1-3 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.12. Шикаять карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шулай ук кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларга кертелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан республикасы норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаган түләүләрне кире кайтару формаларында;

2) шикаять канәгатьләндерелми.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- ТР, Кама-Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мэктэп урамы 1нче йорт.

- ТР, Кама-Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мэктэп урамы 2 нче йорт, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

**Житәкче** **Д.И. Мухамадуллин**